**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

# КАРАР
**сигезенче утырыш**

**4 май 2026 ел** **№ 28** **Teләче ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 ноябрендәге 112 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, «Масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге булеп биру турында» 2026 елның 14 гыйнварындагы 8 номерлы Татарстан Республикасы Рәисенең күрсәтмәсе, «2026 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2025 елның 26 декабрендәге 1163 номерлы Министрлар Кабинетының карары, «Теләче муниципаль районының 2025 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2026 елга бурычлары турында» 2026 елның 11 февралендәге 26 номерлы Теләче муниципаль районы Советының карары нигезендә, «Созидание «идарәче компаниясе» ҖЧҖнең 2026 елның 22 гыйнварындагы 8 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 ноябрендәге 112 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның «А» пунктчасының бишенче абзацына «, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

2) 3 пунктның:

а) «Ж» пунктчасында «җир кишәрлекләре» сүзләрен «җир кишәрлекләренә карата» сүзләренә алмаштырырга;

б) «И» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«И) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясен, икътисадның эшкәртү тармакларын үстерү, яңа төр продукция җитештерү, аеруча прогрессив технологияләрне һәм производстволарны гамәлгә кертү максатларында 2030 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы

карары нигезендә төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать парклары биләгән җир кишәрлекләренә яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) парклары биләгән җир кишәрлекләренә карата җир кишәрлеге милекчеләре эшчәнлек алып бару өчен җир кишәрлегенә резидентлар җәлеп иткән очракта җир салымын түләүдән азат итәргә, башка очракларда җир салымыннан азат итү кулланылмый.

Җир салымы буенча ташламаларны раслау өчен әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркларының яисә индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компаниясе, салым чорыннан соң килә торган елның беренче июненнән дә соңга калмыйча, салым органына, кадастр номерларын күрсәтеп ел дәвамында үз җир кишәрлекләрендә эшчәнлек алып бару өчен резидентлар җәлеп иткән җир кишәрлекләре милекчеләре исемлеген тапшырырга тиеш.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының «б» пунктчасының гамәлдә булуы 2026 елның беренче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru/).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының бюджет һәм салым салу мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы А.Г. Фәтхуллин

Совет Тюлячинского сельского поселения
Теләче авыл җирлеге советы
ИНН 1619000368